**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы**
**Яңа Сумароково авыл җирлеге составына керүче**
**Ростовка авылы торак пунктында гражданнар**
**җыены нәтиҗәләре турында карар**

Ростовка п. 2020 елның 16 ноябре
Ростовка авыл клубы бинасы
15.00 сәгать

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә. № 45-ТРЗ Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында 2020 елның 16 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар Җыенының Бөгелмә муниципаль районының Ростовка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешегә, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм анда катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 2021 елда үзара салым кертүгә риза буласызмы? мәсьәләсе буенча үткәрелгән беркетмәсе төзелде.Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаларны тоту:

- Ростовка авылы юлларын төзекләндерү.өчен

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнардан кергән_89 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 57 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгедән гыйбарәт:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 57 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Халык җыенында катнашучылар тыелып торды- 0.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Сумароково авыл җирлеге составына керүче Ростовка авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Бөгелмә муниципаль районы Яңа Сумароково авыл җирлегенең Ростовка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 2021 елда үзара салым кертүне 1000 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме( Ростовка авылы юлларын төзекләндерү өчен) дигән сорау буенча карар кабул ителде..

3. Әлеге карарны Ростовка авылы торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Интерне челтәрендә рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә. http://bugulma.tatar.ru авыл җирлекләре бүлегенең Яңа Сумароково авыл җирлеге бүлекчәсе)

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Сумарок авыл җирлеге башлыгы Р. М. Паневкина